«РАСЛЫЙМ»

Татарстан Республикасы

Премьер-министры

урынбасары – министр

Р.Т. Борһанов

«___» ________ 2020 нче ел

**Рус телендә белем бирү мәктәпләренең**
**рус телле укучылары өчен туган (татар) телдән**
**2020 нче елда дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру**
**материалларының күрсәтмә варианты**

**Демонстрационный вариант**
**контрольных измерительных материалов для проведения в 2020 году ГИА**
**по родному (татарскому) языку для русскоязычных учащихся**
**школ с русским языком обучения**

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Имтихан эшенең күрсәтмә вариантына аңлатма**

2020 нче елгы күрсәтмә вариант белән танышканда, шуны күз алдында тотарга кирәк: әлеге варианттагы биремнәр 2020 нче елда үтәчәк имтихан эшенең барлык эчтәлек вариантларын да чагылдырмый.

2020 нче елда үтәчәк имтиханда тикшерелергә мөмкин булган эчтәлек элементларының тулы исемлеге төп дәүләт имтиханын үткәрү өчен укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр һәм эчтәлек элементлары кодификаторында китерелә.

Күрсәтмә вариант имтиханда катнашучы һәркемгә һәм киң җәмәгатьчелеккә булачак имтихан эшенең төзелеше һәм биремнәр саны, шулай ук аларның катлаулылык дәрәҗәсе турында күзаллау булдыру мөмкинлеге бирүгә юнәлтелгән.

# Рус телендә белем бирү мәктәпләренең рус телле укучылары өчен туган (татар) телдән 2019 нчы елда дәүләт йомгаклау аттестациясе

## 1 нче вариант

### Эшне башкару өчен күрсәтмә

Татар теленнән төп дәүләт имтиханын тапшыру өчен, 3 сәгать 55 минут (235 минут) вакыт бирелә. Имтихан эше **33 биремне** үз эченә алган **4** бүлектән тора. **1 нче бүлектәге** 13 бирем (1 – 13 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән. **2 нче бүлектәге** 7 бирем (14 – 20 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә. **3 нче бүлектәге** 8 бирем (21 – 28 нче биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала. **4 нче бүлектәге** 29 – 32 нче биремнәр җөмлә калыпларын үзгәртеп язуны күздә тота. Ачык типтагы 33 нче бирем укучыларның язма сөйләмен тикшерүгә юнәлдерелгән.

**Уңышлар телибез!**

### Инструкция по выполнению работы

Время, отведенное на выполнение заданий – 3 часа 55 минут (235 минут). Экзаменационная работа по татарскому языку состоит из четырех разделов, включающих 33 задания. **Раздел 1** (задания по аудированию) включает 13 заданий на понимание аутентичных текстов (задания 1 - 13). **Раздел 2** (задания по чтению) включает в себя 7 заданий (задания 14 - 20). **Раздел 3** (задания по лексике и грамматике) состоит из 8 заданий (задания 21 - 28). **Раздел 4** (задания по письменной речи) состоит из 4 заданий на трансформацию предложений (задания 29 – 32) и задания, в котором предлагается написать личное письмо (задание 33).

**Желаем успеха!**

## Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Кәрим кибеттә нәрсә алырга тели?**

1) чана
2) чаңгы
3) тимераяк

**2** **Сыйныфташлар кая барырга җыеналар?**

1) Милли китапханәгә
2) тарих түгәрәгенә
3) испан теле дәресенә

**3** **Алинә кем белән концертка барган?**

1) дус кызлары
2) апасы
3) әнисе

**4** **Җәен Алинәнең әбисе нишләргә ярата?**

1) бакчада эшләргә
2) чаңгыда йөрергә
3) эше турында сөйләргә

**5** **Кәримнең кем буласы килә?**

1) тарихчы
2) җырчы
3) тәрҗемәче

**6** **Алинәгә кайсы кибет ошый?**

1) “Спортмастер” кибете

2) “Тандем” сәүдә үзәге

3) “Мега” сәүдә үзәге

**7** **Мәктәптә очрашу кайсы көнне булачак?**

1) чәршәмбе көнне

2) сишәмбе көнне

3) шимбә көнне

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Алсуны төрле илләр турында мәгълүмат кызыксындыра.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Сәлимгә саф һавада булу ошый.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Сәлим берничә тапкыр биатлон ярышында булган.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**11** Алсу яшь җырчыларның чыгышларын яратмый.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Киләчәктә Алсуның укытучы буласы килә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Һөнәр сайлау – бик җиңел эш.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

| | | |
|---|---|---|
| **14** | Татар җырларын, татар музыкасын яратучыларны Филармониянең концерт залына чакырабыз. 30 нчы гыйнвар көнне кичке сәгать җидедә татар эстрадасының яшь җырчысы Айгөл Рәхимованың концерты узачак. Айгөл яраткан тамашачысына үзенең иң танылган җырларын башкарачак. Билетлар алырга ашыгыгыз! Билет алу өчен, афиша рәсеменә басу җитә! Көтеп калабыз! Килегез!<br>Белешмә өчен телефон:<br>8 (843) 5-11-12-13 | **Афишада нәрсә турында әйтелә?**<br>1) Филармониядә үткәрелә торган татар җыры фестивале турында.<br>2) Филармониянең концерт залында үтә торган яшь җырчылар конкурсы турында.<br>3) Филармониядә үткәреләчәк яшь җырчының концерты турында. |
| **15** | Кадерле балалар!<br>Февраль аенда мәктәптә танылган татар балалар шагыйре Роберт Миңнуллин белән очрашу үткәрелә. Сезне анда чыгыш ясарга чакырабыз. Очрашуга килгәнче, шагыйрьнең тормышы турында укыгыз, шигырьләре белән танышыгыз һәм яттан өйрәнегез, сораулар әзерләгез. Үткәрү көне һәм вакыты турында укытучыгыз хәбәр итәр. | **Бу хәбәр нәрсә турында?**<br>1) Очрашуда шигырь сөйләргә чакыру турында.<br>2) Мәктәп балалары өчен оештырыла торган шигырь конкурсы турында.<br>3) Шагыйрьнең юбилеен үткәрү турында. |
| **16** | Сәлам, Җәмилә! Нихәл? Укулар барамы? Имтиханнарга әзерләнәсеңме? Минем хәлләрем яхшы. Әти-әниләрем дә исән-саулар. Күп укырга, дәресләргә әзерләнергә кирәк. Мин дә синең кебек имтиханнар бирергә тиеш. Ә инде җәен без синең белән тагын авылда очрашырбыз, бергәләп ял итәрбез. Мин авылны да, әбиләрне дә, сине дә бик сагындым. Июльдә очрашырбыз дип ышанам. Имтиханнарда уңышлар телим.<br>Дустың Әминә | **Электрон хат аша Әминә дус кызына нәрсә турында язган?**<br>1) Җәйге ялга авылга кайта алмавы турында.<br>2) Җәй җитү белән, авылга кайтуы турында.<br>3) Дусты белән бергә ял итәргә теләве турында. |

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Фәнияр Казан шифаханәсендә ярты ел ята инде. Сәламәтлегендә әллә ни үзгәрешләр булмаса да, килү зыян итмәде. Күп кенә язучылар белән танышты. Ә иң әһәмиятлесе, ярты ел эчендә тугызынчы сыйныф программасын тулысынча үзләштерде.

Илсөя дә шифаханәгә еш килеп йөри хәзер. Үзе дә унынчы сыйныфта укыгач, күп вакыт дәресләрен Фәнияр белән бергә әзерлиләр. Ул булганда, Фәниягә рәхәт. Ничектер, егет күңеленә тиз кереп урнашты Илсөя... Ә Илсөянең күңеле сизгер. Егетнең үзен көтеп алганын аңлый. Ярдәм итәргә, ничек тә бер яхшылык эшләргә тырыша. Ул беркөнне, Фәниярнең табибы Галина Измайловна янына кереп:

- Миңа Фәнияр турында сөйләгез әле, - диде. – Аңа нинди ярдәм кирәк?

– Сезнең килеп йөрүегез аның өчен зур ярдәм инде, - диде Галина Измайловна. – Ул бирегә килгәндә, ничектер, кешеләргә ышанмый иде... Ә хәзер бөтенләй башка.

- Аңа кан җибәреп булмыймы? – дип сорады Илсөя. - Мин үз канымны бирер идем.

Кеше язмышы турында кайгыртып йөрүче бу кызга ярату белән карады табиб. Кан җибәреп кенә бастырып булса, врач үз канын җәлләмәс иде.

- Бәлки, аны Мәскәүгә алып барып дәваларга кирәктер?

- Алып барырга мөмкин, әлбәттә. Тик...

Илсөя табибның ни әйтергә теләгәнен аңлады... Күңелсезләнеп, табиб яныннан чыгып китте. Фәниягә ул Галина Измайловна белән сөйләшүен әйтеп тормады. Палатага һәрвакыттагыча елмаеп керде.

- Яныма утыр әле, Илсөя, - диде егет. Ә хәзер кулыңны бир, язмышыңны укып карыйм.

Илсөя, оялып кына, аңа кулын бирде. Егет кулдагы сызыкларга караган булып сөйләп китте:

- Эшең бик югарыда икән. Шуңа күрә егетләргә өстәнрәк карарга өйрәнгәнсең...

Илсөя, гадәттә, Фәнияр янына кичләрен килә. Шуңа күрә, шаярып, беркөнне Фәнияр болай диде:

- Минем хәзер ике кояшым бар, Илсөя. Берсе аның иртәнге алтыларда тәрәзәдән төшә, икенчесе кичке алтыларда ишектән керә.

- Ишектән кергән кояшны күргәнем юк әле минем, кайда соң ул синең кояшың?

- Менә ич, янымда утыра, - диде егет.

Фәниярнең сүзләреннән Илсөя кызарды. Аңа бу сүзләрне ишетү рәхәт иде.

*(Фәнис Яруллиннан)*

**17** Шифаханәдә яту Фәниягә нинди файда китергән?

1) Аның сәламәтлеге тиз арада яхшырган.

2) Шифаханәдә ятуның зыяны булмаган.

3) Ул ярты ел ял итеп яткан.

**18** Илсөя килгәндә, Фәнияр үзен ничек хис итә?

1) Илсөянең килүе егеткә ошамый.

2) Бу көнне Фәниярга күңелсез була.

3) Илсөя килүгә егет бик шатлана.

**19** Илсөя табиб белән нәрсә турында сөйләшә?

1) Егеткә ярдәм итәргә теләвен әйтә.

2) Табибларга ышанмавы турында сөйли.

3) Егетне чит илдә дәвалау турында сөйләшә.

**20** Фәнияр кызга яратуын ничек белдергән?

1) Ул кызны кичләрен саф һавада йөрергә чакырган.

2) Ул аңа чәчәкләр бүләк иткән.

3) Ул аны кояш белән чагыштырган.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

### Бәйрәмнәр

Россиядә барлык кешеләрнең иң яраткан бәйрәме — Яңа ел. Бу бәйрәмгә (21) ... ук әзерләнә башлыйлар: дусларга һәм туганнарга бүләкләр сатып алалар, чыршы бизиләр. Яңа ел — гаилә бәйрәме. 31 нче декабрь көнне төнге сәгать уникедә бөтен гаилә (22) ... табынына җыела. Барысы да бер-берсен Яңа ел белән (23) ..., бәхет телиләр, ә аннары һәркем чыршы төбеннән үзенә бүләк таба.

Ел саен 23 нче февраль көнне Россиядә Ватанны (24) ... көнен бәйрәм итәләр. Бу көнне хәрбиләрне генә түгел, һәр (25) ... бәйрәм белән котлыйлар.

Россиядә һәм Татарстанда (26) ... мартта барлык хатын-кызларны Халыкара хатын-кызлар көне белән котлыйлар. Бу көнне аларга чәчәкләр (27) ..., матур сүзләр әйтәләр.

30 нчы августта Татарстанда Республика көнен бәйрәм итәләр. Бу көнне урамнарда төрле концертлар, тамашалар, уеннар үткәрәләр. Кешеләр рәхәтләнеп (28) ..., җырлыйлар, бииләр.

**21** 1) алга 2) алдан 3) алдыннан

**22** 1) бәйрәмгә 2) бәйрәмдә 3) бәйрәм

**23** 1) котладылар 2) котлыйлар 3) котлагач

**24** 1) саклаучылар 2) саклаган 3) саклыйлар

**25** 1) хатын-кызны 2) әти-әнине 3) ир-атны

**26** 1) уникенче 2) сигезенче 3) утызынчы

**27** 1) бүләк итәләр 2) бүләк итүчеләр 3) бүләк бирделәр

**28** 1) эшлиләр 2) җавап бирәләр 3) күңел ачалар

## Раздел 4

***Прочитайте задания 29 - 32. Допишите второе предложение так, чтобы оно по значению совпадало с первым. Используйте не больше трех слов в каждом предложении. В бланк ответов перепишите только пропущенные слова, без интервала как в примере.***

**ҮРНӘК** **0** Кичә, авыру сәбәпле, мин укуга бара алмадым.

**Кичә мин мәктәпкә бара алмадым, чөнки ...**

| | |
|---|---|
| **0** | **Авырдым** |

**29** Ял көнне без караган тамаша күңелле булды.

**Якшәмбе көнне без күңелле ...**

**30** Сыйныфташымның абыйсын спорт ярышында җиңүе белән котладым.

**Сыйныфташымның абыйсы ярышта ..., шуңа күрә мин аны тәбрик иттем.**

**31** Дустыма шалтыратып, аның хәлләрен белдем, чөнки ул инде ике атна авырый.

**Дустым авырганга күрә, мин аңа ... һәм хәлләрен сораштым.**

**32** Сәламәт булу өчен, күбрәк яшелчәләр ашарга кирәк, чөнки аларда витаминнар бик күп.

**Мин сәламәт булырга телим, шуңа күрә яшелчәләр күп ... .**

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**

**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

> *... Миңа табиб һөнәре бик ошый. Гаиләбездә әти-әнием дә, әби белән бабам да табиблар. Табиблар кешеләрнең сәламәтлеге турында кайгырталар, аларны дәвалыйлар.*
>
> *... Сиңа кайсы һөнәр күбрәк ошый?... Син кем булырга хыялланасың? ... Бу һөнәр кешеләре нинди булырга тиеш?*

**ҖАВАПЛАР**

| Биремнәр | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 2 | 3 |
| 3 | 2 |
| 4 | 1 |
| 5 | 3 |

| | |
|---|---|
| 6 | 3 |
| 7 | 1 |
| 8 | 1 |
| 9 | 1 |
| 10 | 2 |
| 11 | 2 |
| 12 | 1 |
| 13 | 2 |
| 14 | 3 |
| 15 | 1 |
| 16 | 3 |
| 17 | 2 |
| 18 | 3 |
| 19 | 1 |
| 20 | 3 |
| 21 | 2 |
| 22 | 3 |
| 23 | 2 |
| 24 | 1 |
| 25 | 3 |
| 26 | 2 |
| 27 | 1 |

| | |
|---|---|
| 28 | 3 |
| 24 | 1 |
| 25 | 3 |
| 26 | 2 |
| 27 | 1 |
| 28 | 3 |
| 29 | ТАМАШАКАРАДЫК/ТАМАШАКҮРДЕК |
| 30 | ҖИҢГӘН/ҖИҢДЕ/ҖИҢҮ ЯУЛАГАН |
| 31 | ШАЛТЫРАТТЫМ |
| 32 | АШЫЙМ |

## Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар

**Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.**

**Беренче сорау. Кәрим кибеттә нәрсә алырга тели?**
**Алинә**: Сәлам, Кәрим! Нихәл? Нәрсә эзлисең бу бүлектә?
**Кәрим**: Сәлам, Алинә! Миңа яңа чаңгы алырга кирәк. Иртәгә мәктәптә ярышлар була. Һәр укучы катнашырга тиеш дип әйтте физкультура укытучысы. Мин җиңәргә телим, шуңа күрә яңа чаңгы аласым килә.
**Алинә**: Алай икән! Син чаңгыда яхшы шуасыңмы? Сыйныфыгызда тагын көчле чаңгычылар бармы соң?
**Кәрим**: Әйе, мин яхшы шуам, ләкин көчле малайлар да бар. Аларның да җиңәселәре килә. Шуңа күрә ярыш бик кызык булачак. Син дә карарга кил. Минем өчен җан атарсың.
**Алинә**: Ә ярышлар сәгать ничәдә башлана? Кайда була?
**Кәрим:** Сәгать унда башлана дип әйттеләр. Ярыш мәктәп янындагы урманда булачак.
**Алинә**: Яхшы, Кәрим, мин килергә тырышырмын, дус кызларымны да чакырырмын. Синең өчен җан атарбыз. Син җиңәрсең!
**Кәримә**: Рәхмәт, Алинә! Син - чын дус!
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Икенче сорау. Сыйныфташлар кая барырга җыеналар?**
**Алинә**: Кәрим, сәлам! Кая ашыгасың?
**Кәрим**: Сәлам, Алинә! Без сыйныфташларыбыз белән испан теле курсларына язылдык. Миңа университетка барырга кирәк. Метро белән тизрәк булачак. Метро станциясенә барам. Ә син кая юл тоттың?
**Алинә:** Миңа да шәһәр үзәгенә барырга кирәк. Әйдә, бергә киттек метрога. Безгә тарих укытучысы реферат язарга кушты, шуңа күрә мин Милли китапханәгә барырга булдым. Анда кызыклы китаплар табармын дип уйлыйм.
**Кәрим:** Нинди темага язарга кирәк? Бәлки бездә дә кирәкле китаплар бардыр. Әтием тарих белән кызыксына, аннан ярдәм сорарга мөмкин.
**Алинә:** Шулаймыни? Кызык икән. Белмәгән идем. Ярар, китапханәдән кайткач, мин сиңа шалтыратырмын. Миңа татар мәгърифәтчеләре турында язарга кирәк. Сиңа курсларда уңышлар телим, Кәрим. Испан теле миңа да бик ошый, ләкин барысына да вакыт җитми. Кичен хәбәрләшербез.
**Кәрим:** Ярар, рәхмәт, Алинә. Сау булып тор. Хәерле юл сиңа!
**Алинә:** Рәхмәт, Кәрим!
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Өченче сорау. Алинә кем белән концертка барган?**

**Кәрим:** Алинә, якшәмбе көнне концертка бардыңмы? Ничек булды?

**Алинә**: Әйе, әлбәттә, бардым. Бик ошады. Яшь татар җырчылары концертында беренче тапкыр булдым.

**Кәрим:** Кем белән бардың соң? Дус кызларың беләнме?

**Алинә:** Юк. Мин апам белән бардым. Ул музыка училищесында укый бит. Ул концертларга бик еш йөри. Зур концерт залында булдык.

**Кәрим:** Алай икән. Икенче тапкыр барганда, миңа да әйт. Мин дә музыка белән кызыксынам. Татар артистларының җырларын радиодан да тыңлыйм.

**Алинә:** Ярар, сөйләштек, Кәрим.

**[2 секунд пауза]**

**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау. Җәен Алинәнең әбисе нишләргә ярата?**

**Кәрим:** Алинә, сәлам! Бүген тагын концертка барасыңмы?

**Алинә:** Юк. Бүген әбиләргә кунакка барам. Бүген әбиемнең туган көне. Аңа җитмеш яшь тула. Гаиләбез белән аны котларга барабыз.

**Кәрим:** Әбиең үзе генә яшиме?

**Алинә:** Әйе, үзе генә яши. Ләкин ул бик актив тормыш алып бара. Кышын ул чаңгыда йөри. Җәен бакчада эшли. Яшелчәләр утырта, чәчәкләр үстерә. Мин дә каникулда аның белән бакчада булам. Аңа булышам.

**Кәрим:** Шулай инде, әбиләр һәрвакыт хәрәкәттә. Минем ике әбием бар. Алар авылда яшиләр. Җәй саен мин аларда рәхәтләнеп ял итәм. Җәен авылда бик күнелле, бик күп балалар каникулга кайта. Без бергәләп күлдә су коенабыз, балыкка йөрибез.

**Алинә:** Ә мин әбием белән сөйләшеп утырырга яратам. Ул үзенең яшьлеге, яраткан эше турында миңа сөйли. Ул озак еллар университетта укытучы булып эшләгән, студентларга белем биргән. Хәзер дә укучылары бәйрәмнәрдә аңа шалтыраталар һәм котлыйлар.

**Кәрим:** Ярар. Әбиеңә саулык-сәламәтлек телим. Бәйрәмегез күңелле үтсен!

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Бишенче сорау. Кәримнең кем буласы килә?**

**Алинә:** Кәрим, әйт әле, синең кем буласың килә?

**Кәрим**: Миңа күп һөнәрләр ошый, Алинә. Кайсы һөнәрне сайлармын, әлегә төгәл генә белмим кебек. Ә син, Алинә, кем булырга хыялланасың?

**Алинә:** Син беләсең бит, Кәрим, мин музыка белән кызыксынам, шуңа күрә апам кебек музыка училищесына укырга керергә телим.
**Кәрим**: 9 нчы сыйныфтан соңмы?
**Әминә:** Әйе, анда тугызынчы сыйныфтан соң укырга керәләр, дүрт ел укыйлар. Аннары инде консерваториядә югары белем алырга мөмкин. Менә шулай. Кәрим, әйт инде, мәктәпне тәмамлагач, син кайда укырга телисең?
**Кәрим**: Синең музыкант буласың килә, Алинә, ә минем тәрҗемәче буласым килә. Телләр белү – зур байлык бит. Төрле илләрне күрергә, төрле кешеләр белән танышырга мөмкин.
**Алинә:** Менә ничек кызык! Ә үзең белмим дисең. Тәрҗемәче һөнәре миңа да ошый.
**Кәрим**: Хыялларыбыз тормышка ашсын, Алинә!
**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Алтынчы сорау. Алинәгә кайсы кибет ошый?**
**Алинә:** Кәрим, сәлам, бүген кичен нишлисең?
**Кәрим:** Белмим әле. Планнарым юк. Син кая барырга телисең?
**Алинә:** Минем кибеткә барып, яңа кроссовкалар аласым килә. Әйдә, минем белән бар әле, сайларга булышырсың.
**Кәрим:** Ә-ә-ә, минем белән кибеткә барасың киләме? Сина кайсы кибет ошый соң?
**Алинә:** Гадәттә, мин өс киемнәрен дә, аяк киемнәрен дә “Мега” сәүдә үзәгеннән алырга яратам. Ә кроссовкалар алганым юк. Кайсы кибеткә барыйк соң?
**Кәрим:** Әйдә, “Спортмастер” кибетенә барыйк. Анда хәзер ташламалар.
**Алинә:** Рәхмәт, Кәрим. Әйдә, киттек.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Җиденче сорау. Очрашу кайсы көнне булачак?**
**Алинә**: Кәрим, гафу ит, татар шагыйрьләре белән очрашу кайчан булачак?
**Кәрим:** Минемчә, егерме дүртенче апрельдә була дип әйтте сыйныф җитәкчебез.
**Алинә:** Атнаның кайсы көненә туры килә? Очрашу шимбә көнне булачакмы?
**Кәрим:** Әйдә, календарьдән карыйбыз. Юк, шимбә түгел. Егерме дүртенче апрель чәршәмбе була. Бу көнне кая да булса барасың бармы?
**Алинә**: Әйе. Бу көнне “Татар кызы” конкурсының финалы бит. Мин шунда катнашам. Очрашуда була алмаячакмын. Бу турыда сыйныф җитәкчесенә әйтергә кирәк.

**Кәрим**: Ярар. Борчылма. Мин сиңа очрашу турында сөйләрмен. Конкурста уңышлар телим!
**Алинә**: Рәхмәт инде сиңа, Кәрим!

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**[пауза 20 секунд]**
**Сәлим**: Сәлам, Алсу!
**Алсу**: Сәлим, сәлам!
**Сәлим**: Алсу, син буш вакытыңда нишләргә яратасың?
**Алсу:** Буш вакытым күп түгел. Шулай да, ял көннәрендә дус кызларым белән аралашырга, алар белән бергәләп паркка, кафега барырга яратам. Ә өйдә булганда, мин Интернеттан төрле илләр турында мәгълүматлар укырга яратам. Ә син буш вакытыңны ничек үткәрәсең, Сәлим?
**Сәлим**: Мин телевизордан спорт ярышларын карарга яратам. Миңа бигрәк тә биатлон ошый. Ял көннәрендә дусларым белән стадионга футбол уйнарга йөрим, саф һавада күбрәк булырга яратам. Еш кына без гаиләбез белән әбиләргә кунакка барабыз. Анда бергәләп аралашабыз, яңалыклар турында сөйләшәбез, рәхәтләнеп ял итәбез.
**Алсу:** Ә киногa, концертларга барырга яратасыңмы, Сәлим?
**Сәлим:** Әйе, кызык фильмнар булганда, абыем белән кинога барырга яратам. Концертларга бик сирәк йөрим. Ә менә татар театрында берничә тапкыр булдым инде. Әнием һәр премьераны карарга тырыша, абыем белән мине дә алып бара.
**Алсу:** Кызык! Сине шулай театр яратучы дип уйламаган идем. Ә мин татар җырчыларының концертларына барырга яратам, бигрәк тә яшь башкаручыларның чыгышлары ошый. Гастрольләргә килгән рус җырчыларының, рок төркемнәренең концертларында да булырга тырышам.
**Сәлим:** Син музыкант булырга җыенасыңмы әллә, Алсу? Син бит үзең дә бик матур җырлыйсың, төрле халыкара конкурсларда катнашасың, дипломнар аласың.
**Алсу:** Юк, Сәлим, музыка белән мин үзем өчен генә шөгыльләнәм, сәхнәдә чыгыш ясау миңа бик ошый, ләкин профессиональ җырчы булу турында хыялланмыйм. Беләсеңме, миңа кайсы һөнәр ошый?
**Сәлим:** Юк шул, Алсу! Әйдә, әйт. Һөнәр сайлау җиңел эш түгел.
**Алсу:** Минем укытучы буласым килә. Инглиз теле укытучысы. Менә шулай, Сәлим!
**Сәлим:** Шәп һөнәр сайлагансың, Алсу! Афәрин!

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**У вас есть 6 минут, чтобы внести ответы в специальный бланк.**

**Шәхси хат язу биремен бәяләү критерийлары**

*1 нче таблица*

| К | Бәяләү критерийлары | 3 балл | 2 балл | 1 балл | 0 балл |
|---|---|---|---|---|---|
| К1 | Коммуникатив бурычны үтәү | ***Эш тулысынча башкарылган:*** 3 сорауга да тулы җавап бирелгән. Мөрәҗәгать итү, саубуллашу һәм имзалау фразалары дөрес сайланган. Алынган хатка рәхмәт белдерелгән | ***Эш башкарылган:*** 3 сорауга да җавап бирелгән, әмма берсенә бирелгән җавап тулы түгел. Хат стилен бозган 1-2 төгәлсезлек бар ***һәм/яки*** алынган хатка рәхмәт белдерелмәгән | ***Эш өлешчә башкарыл-ган***: 2 сорауга гомуми җавап бирелгән, әмма 1 сорауга бирелгән җавап тулы түгел ***яки*** бер сорауга гомумән җавап юк. Хат стилен бозган 3 яки күбрәк төгәлсезлек бар, итагатьлелек формалары сакланмаган | ***Эш башкарылмаган:***2 сорауга җавап бирелмәгән ***яки*** текстның күләме тулмый |
| К2 | Текстны оештыру | | Текст логик эзлеклелектә төзелгән һәм абзацларга бүленештә хаталар юк; тел чаралары дөрес кулланылган; хатның төзелеше | Текст, гомумән алганда, логик эзлеклелектә төзелгән, ләкин логик бәйләнешләрдә ***һәм /яки*** абзацларга бүленештә ***яки*** | Текст төзелешендә логик эзлеклелек сакланмаган; язма текст төзелешендә 3 яки күбрәк хата бар, ***яки*** хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | язма этикет нормаларына туры килә | хатның төзелешендә 1-2 төгәлсезлек бар | килми. |
| К3 | Текстның лексик-грамматик төзелеше | Коммуникатив бурычны үтәү өчен кирәк булган төрле лексик һәм грамматик чаралар файдаланылган (текстны аңлауга зыян китермәгән 1-2 төгәлсезлек рөхсәт ителә) | Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (3-4 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***яки*** тел хаталары юк, ләкин артык гади лексик һәм грамматик чаралар кулланылган | Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (5-6 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***һәм /яки*** текстны аңлауга зыян китерә торган 1-2 грамматик хата бар | Текстны аңлауга зыян китерә торган хаталар 6 дан күбрәк |
| К4 | Орфография һәм пунктуация | | Орфографик һәм пунктуацион хаталар юк, **яки** текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 1-2 хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 3-4 орфографик һәм пунктуацион хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерә торган орфографик һәм пунктуацион хаталар 4 тән күбрәк |

Шәхси хат язу биреме К1-К4 критерийлары буенча тикшерелә. Максималь **10 балл** алырга мөмкин.

Текстның эчтәлеге биремгә туры килмәсә (язма хат характерында булмаса, **тәкъдим ителгән сорауларга җавап урынына башка мәгълүмат язылса**, тәкъдим ителгән хат күчереп кенә язылса) бу бирем өчен 0 балл куела.

Хатның күләме 3**0** сүздән ким булса, К3 һәм К4 критерийлары буенча максималь балл куелмый.

Эшнең күләмен билгеләгәндә, беренче сүздән алып соңгысына кадәр (шулай ук адрес, язылу вакыты, имза да) исәпкә алына. **Хатта укучы үзенең чын исемен, адресын күрсәткән очракта эш тикшерелми.**

**Имтихан эше өчен түбәндәге билгеләр куела:**

0 - 12 балл – «2» ле билгесе;

13 - 20 балл – «3» ле билгесе;

21 - 31 балл – «4» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен (1-13 нче биремнәр) баллары 7 дән кимрәк булмаска тиеш.

Әгәр укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен баллары 7 дән кимрәк булса, «3» ле билгесе куела.

32 - 42 балл – «5» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен баллары 10 нан кимрәк булмаска тиеш. Әгәр укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен баллары 10 нан кимрәк булса, «4» ле билгесе куела.